# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Сәхрә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

26.10.2020 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Сәхрә торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2020 елның 26 октябрендә 12 сәгать 00 минутта уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сәхрә торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым акчалары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

- Шаршады авылында Зәйнетдинов урамы буенча юлга вак таш сатып алу һәм каплау;
-Сәхрә авылы юлларын кардан чистарту;
- тирәнлек насосы сатып алу, Сәхрә авылында су скважинасын чистарту;
-янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә хезмәт килешүе буенча түләү, янгын сүндерү машинасы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 45 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 28 кеше, бу 62 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 28 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Сәхрә торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сәхрә торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым акчалары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Шаршады авылында Зәйнетдинов урамы буенча юлга вак таш сатып алу һәм каплау;
- Сәхрә авылы юлларын кардан чистарту;
- тирәнлек насосы сатып алу, Сәхрә авылында су скважинасын чистарту;
- янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә хезмәт килешүе буенча түләү, янгын сүндерү машинасы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы В.Х. Баһаветдинов